**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӨҖЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**УЗЮМСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Таш-Чишма. Тел. 3-50-10

# КАРАР

**«05» ноябрь 2019г.** **№ 15**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында күмү һүм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 нче номерлы "2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә мунципаль районының Өҗем авыл җирлегендә № 1 нче һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 ел 1нче ноябрьдән гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (http:pravo.tatarstan.ru) веб–адресы буенча Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Өҗем авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Т.Вәлиев

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 ел 5 ноябрь № 15 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3937-43 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 475-51 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1533-53 |
| **Барлыгы** | **5946-47** |

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 ел 5 ноябрь № 15 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 213-97 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3723-46 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 475-52 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1533-52 |
| **Барлыгы** | **5946-47** |